СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы Тау,423181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

Тубылгы Тау авыл җирлеге советы утырышы
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
КАРАРЫ

2021 елның 29 нчы апреле

№ 10-28

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 июнендәге 28-68 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгытау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү Кагыйдәләре» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгытау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, шулай ук, Тубылгытау авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү объектларын карап тотуга, чисталыкка һәм тәртипкә карата бердәм таләпләр билгеләү, тулаем төзекләндерү дәрәҗәсен күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 июнендәге 28-68 номерлы «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгытау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү Кагыйдәләре» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә укырга: «территорияне төзекләндерү - муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән чаралар комплексын тормышка ашыру, муниципаль берәмлек территориясенең санитар һәм эстетик торышын тәэмин итүгә һәм яхшыртуга, мондый территорияләрдә урнашкан торак пунктлар территорияләрен, шул исәптән гомуми файдаланудагы территорияләрне, җир кишәрлекләрен, биналар, төзелмәләрне, корылмаларны, якын-тирә территорияләрне карап тотуга юнәлдерелгән эшчәнлек;».

1.2 44 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә укырга: "әгәр мондый җир участогы барлыкка килгән һәм чикләре Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән билгеләнгән булса, аның янәшәсендәге территория - гомуми файдаланудагы территория;".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, Яңа

Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм территорияләрне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Тубылгытау авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Исмагилов